СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 12-15 от « 11 » августа 2022 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәне гамәлдән чыгару хакында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2022 елның 12 июлендәге Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан агымдагы елның II кварталында Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелгән актларда ачыкланган хокук бозулар турындагы 09/13-09/3549 номерлы мәгълүматы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасының Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2021 елның 12 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәне раслау хакында» 11-9 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәне гамәлдән чыгарырга.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2022 елның 25 февралендәге «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге № 248-ФЗ Федераль закон чараларын гамәлгә ашыру турында 2-12 номерлы карарының 1 пунктын гамәлдән чыгарырга.

3. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати-коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) урнаштырырга.

000082

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мамадыш муниципаль районы Советының җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе

А.П.Иванов